# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Ямурза торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**11 нче ноябрь, 2024 нче ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның «11» нче ноябрендә 10 сәгать 00 минутта уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2025 нче елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Ямурза торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, укытуның көндезге формасында белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында һәм иректән мәхрүм итү урыннарында хезмәт итүгә чакырылган затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр контракты буенча, мобилизованныйлар) һәм аларның гаилә әгъзаларын (әти-әниләре,тормыш иптәшләрен, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итеп, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Торак пункт территориясен төзекләндерү (торак пункт урамнарының карын чистарту, дизель ягулыгы һәм май сатып алу, тракторчының килешүе буенча эш хакы тулэу).

2. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау һәм электр энергиясен җиһазлар (электр товарлары һәм урам яктырту лампалары сатып алу) тапшыруны гамәлгә ашыру.

3. Халыкны су белән тәэмин итү (ремонт, хезмәт күрсәтү, тирәнлек насослары, материаллар һәм су белән тәэмин итү өчен башка хезмәтләр).

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 128 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 75 кеше, бу 59 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“РИЗА” позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 75 кеше тавыш бирде;

"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Ямурза торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. 2025 нче елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Ямурза торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, укытуның көндезге формасында белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында һәм иректән мәхрүм итү урыннарында хезмәт итүгә чакырылган затлардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләр контракты буенча, мобилизованныйлар) һәм аларның гаилә әгъзаларын (әти-әниләре,тормыш иптәшләрен, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итеп, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 700 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә .

3. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәгеләргә җибәрергә:

1. Ямурза торак пункты территориясен төзекләндерү:
- *юлларны кардан чистарту ;*
-*дизель ягулыгы, МТЗ-82 тракторы өчен май сатып алу;*
- *шартнамә буенча тракторчының эшенә түләү.*

2. *Ямурза* торак пункты чикләрендә РФ законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- *халыкны су белән тәэмин итүне карап тору(ремонт, хезмәт күрсәтү, тирән насослар һәм материаллар сатып алу һәм Ямурза торак пунктын су белән тәэмин итү өчен башка хезмәтләр башкару).*

3. *У*рамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:

һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау:
*-Ямурза торак пунктында урамнарны яктырту өчен лампалар, фонарьлар сатып алу, урнаштыру;*
*- урамнарны яктырту буенча башка чыгымнар.*

4. Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:
*- янгын сүндерү җиһазлары сатып алу һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар.*

5. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау:
*- материаллар сатып алу һәм җәяүлеләр күперләрен ремонтлау өчен башка чыгымнар.*
6. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту:
*- Совет урамына вак таш сатып алу, җәю.*

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (https://agryz.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы М.М.Мөхәммәдиев

Совет Салаушского сельского поселения
Салагыш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002491